| 16. | Тема 16. Ш.Маннур, Х.Туфан иҗаты. | 6 | | Хәсән Туфан (1900-1981): гүзәл гамьле иҗат. Ш.Маннурның беренче шигъри тәҗрибәләре. Хезмәт пафосын һәм социалистик ярышны гәүдәләндергән Колчеданлы таулар итәгендә, Чуен ташкыннар. | 4 | письменная работа |

| N | Раздел Дисциплины | Семестр | Неделя семестра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудоемкость (в часах) | Формы контроля самостоятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 17. | Тема 17. И.Гази, Ф.Хөсни иҗаты. Г.Әпсәләмов, М.Әмир иҗаты. Ә.Еники, Г.Бәширов иҗаты. | 6 | | Сугыштан соңгы татар прозасында тематиканың киңәюе, зур күләмле, киң колачлы әсәрләр иҗат ителүе. И.Газинең беренче иҗат тәҗрибәләре. | 4 | тестирование |
| 18. | Тема 18. Кереш. Рун-уйгур язулы истәлекләр. Гарәп язулы истәлекләр. Болгар чоры әдәбияты. Алтын Урда чоры әдәбияты. Казан ханлыгы чоры әдәбияты. XV-XVI йөзләрдә иҗат иткән әдипләр. | 1 | | М. Кашгарый, Й. Баласагунлы, Ә. Йүгнәки, ә. Ясәви, С. Бакырганый иҗатлары турында кыскача белешмә. Кол Гали. Кыйссаи Йосыф поэмасы. Рабгузый, Харәзми, М. Болгари, Ә. Үргәнчи әсәрләре. Х. Кятиб. | 44 | устный опрос |
| 19. | Тема 19. XVII йөз әдәбиятына күзәтү. XVIII йөз әдәбияты. Кереш. Курсның максаты, бурычлары, татар әдәбияты тарихында тоткан урыны, башка предметлар белән бәйләнеше. XIX йөзнең 1 яртысында татар поэзиясе. XIX йөзнең II яртысында (1861-1905) татар әдәбияты. Йомгак. | 1 | | М. Колый иҗаты. Габдессәлам, Г. Мөслим, Әхмәдбик, Т. Ялчыгол. Г. Утыз Имәни. Тәрҗемәи хәле. Иҗатына гомуми күзәтү. XIX йөзнең 1 яртысында әдәбиятның нигездә шигъри характерда үсеше. | 43 | письменная работа |

| N | Раздел Дисциплины | Семестр | Неделя семестра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудоемкость (в часах) | Формы контроля самостоятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 20. | Тема 20. Кереш лекция. 1960-1985 нче еллар татар әдәбиятына гомуми күзәтү. | 7 | | Татар әдәбиятының элекке чорлардан килгән традицияләрен жанрлар, тема - проблемалар һәм әдәби-сәнгать чаралары ягыннан дәвам итү. | 24 | реферат |
| 21. | Тема 21. Татар прозасына гомуми күзәтү. | 7 | | Бөек Ватан сугышына багышланган әсәрләрдә татар ир-егетләренең яу кырындагы язмышларын киң, тулы һәм конкрет итеп тасвирлау. Ә.Еникиның Без дә солдатлар идек(1971). | 24 | устный опрос |
| 22. | Тема 22. Гомәр Бәширов, Аяз Гыйләҗев, А.Расих иҗатларына гомуми күзәтү. | 7 | | Гомәр Бәширов (1901-1999) Г.Бәшировның озын һәм катлаулы тормышы, иҗат юлы. Беренче иҗат тәҗрибәләре, журналист һәм язучы буларак формалашуы. | 25 | письменная работа |
| 23. | Тема 23. Татар әдәбиятында тарихи тема. Нурихан Фәттахов, М.Хабибуллин | 7 | | М. Хәбибуллин (1927). Язучының тормышы һәм эшчәнлеге. Төрле һөнәр ияләренең рухи-әхлакый йөзләрен ачуга багышланган Икмәк кадере, Тау белән тау очрашмаса да(1970). | 26 | письменная работа |


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

| N | Раздел Дисциплины | Семестр | Неделя семестра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудоемкость (в часах) | Формы контроля самостоятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 24. | Тема 24. Татар әдәбиятында авыл прозасы. М.Мәһдиев, Р.Төхфәтуллин, Э. Еники иҗатлары. | 7 | | МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ (1930-1995) Күренекле шәхес, язучы, әдәбият галиме, публицист, педагог Мөхәммәт Мәһдиевның тормышы һәм иҗат юлы. | 28 | устный опрос |
| 25. | Тема 25. 1960-1985 нче еллар татар поэзиясенә гомуми күзәтү. | 8 | | 1960-1985 елларда поэзия. Поэзиядә кеше шәхесенә игътибар арту. Лирик агымның көчәюе Өлкән буын шагыйрьләренең иҗат активлыклары үсү. Х.Туфан, С.Хәким, Ш.Маннур. | 15 | реферат |
| 26. | Тема 26. 1960-1985 нче еллар татар драматургиясенә гомуми күзәтү | 8 | | 1965-85 еллар драматургиясендә сыйфат үзгәрешләре.Драматургиягә килгән бер төркем авторлар - Хәй Вахит, Шәриф Хөсәенов, Туфан Миңнуллин. | 16 | письменная работа |
| 27. | Тема 27. С.Сөләйманова, И. Юзеев тормыш һәм иҗат эшчәнлегенә гомуми күзәтү. | 8 | | С.СӨЛӘЙМАНОВА (1926-1980). Тормыш юлы һәм иҗади үсеше турында мәгълүмәтләр.Тормыишы тирән тоемлавы. | 16 | устный опрос |



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

| N | Раздел Дисциплины | Семестр | Неделя семестра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудоемкость (в часах) | Формы контроля самостоятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 28. | Тема 28. Татар поэзиясендә юмор. Г.Афзал, Ш.Галиев иҗатларына гомуми күзәтү | 8 | | Г. АФЗАЛ (1921-2003) Г. Афзалның тормыш һәм иҗат юлы. 1955 елда беренче шигырьләре белән олы әдәбиятка юл яруы "Кар сулары" ( 1957 ), "Вөҗдан сүзе" (1958). | 16 | устный опрос |
| 29. | Тема 29. Ш.Хөсәенов, Х.Вахит. Н.Исәнбәт тормыш һәм иҗат эшчәнлеге | 8 | | Ш. ХӨСӘЕНОВ (1929-1999) иҗаты. Язучы драматур буларак иң беренче Профессор кияве( 1952) комедиясе белән танылуы. Зөбәйдә адәм баласы (1961). | 16 | тестирование |
| 30. | Тема 30. Ю.Әминев, Р.Хәмид тормыш һәм иҗат эшчәнлеге | 8 | | Әминов (1921-1982) иҗаты Тамырлар(1961), Гөлчәчәк (1963), Минем җинаятем(1971), Гөлҗәннәтнең җәннәте (1973), Кан кардәшләр, Сөймим дисәң дә... (1976) һ.б. әсәрләре, Кошның да үз канаты була (1967) | 16 | письменная работа |

| N | Раздел Дисциплины | Семестр | Неделя семестра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудоемкость (в часах) | Формы контроля самостоятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 31. | Тема 31. Т.Миңнуллин тормыш һәм иҗат эшчәнлегенә гомуми күзәтү. | 8 | | Т. МИҢНУЛЛИН (1935 -2012) Т.Миңнуллин - күренекле драматург, публицист, прозаик, әдәби хәрәкәтне әйдәп баручы.1960-1970 елларда язылган "Нигез ташлары"(1968), "Ир-егетләр"(1971). | 16 | реферат |
| 32. | Тема 32. Х.Туфан, С.Хәким иҗатларына гомуми күзәтү. | 9 | | Хәсән Туфан. Иҗатына күзәтү. "Ә үткәнгә хатлар бармыйлар", "Кармәт истәлекләре". Әсәрләрнең төп проблематикасы һәм яңалыгы. Сибгат Хәким. Иҗатына күзәтү. "Гел кояшка карый тәрәзәләрем". | 36 | устный опрос |
| | Итого | | | | 743 | |

### 5. Образовательные технологии, включая интерактивные формы обучения

Вузовское освоение курса 'История родной литературы' предполагает использование как традиционных, так и инновационных образовательных технологий, а также настоятельно требует рационального их сочетания. Традиционные образовательные технологии подразумевают использование в учебном процессе таких методов работ, как лекция, практическое занятия, семинар и др. При проведении занятий планируется использование активных и интерактивных форм занятий (деловых и ролевых игр, проектных методик, мозгового штурма, коммуникативного тренинга, иных форм) в сочетании с внеаудиторной работой.

### 6. Оценочные средства для текущего контроля успеваемости, промежуточной аттестации по итогам освоения дисциплины и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы студентов

**Тема 1. Кереш.Курсның максаты, бурычлары, татар әдәбияты тарихында тоткан урыны, башка предметлар белән бәйләнеше. XIX гасырның 1 яртысы (1800- 1860)татар әдәбиятына гомуми күзәтү. Әлегечорда иҗтимагый- тарихи вакыйгалар. XIX йөзнең 1 яртысында татар поэзиясе.**

устный опрос , примерные вопросы:

XIX йөзнең 1 яртысында әдәбиятның нигездә шигъри характерда үсеше. Ә.Каргалый иҗатында дини суфыйчылык мотивларының дөньяви башлангыч белән үрелеп үсүе. Гомәр Мөхәммәт улы әсәрләренең татар әдәбиятына алып килгән яңалыгы. Һ.Салихов мәрсияләре. Ш.Зәкинең әхлакый сафлыкны идея итеп үзгәртүе. Г.Кандалыйның мәхәббәт җырчысы буларак алып килгән яңалыгы. К.Насыйри мәгърифәтче язучы, энциклопедик галим. XIX йөзнең 2 яртысында поэзия. Поэзиянең чынбарлыкка, халыкны борчыган мәсьәләләргә якынлыгы. Мәгърифәтчелек идеяләренең тормыштагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә поэзиягә торган саен тирәнрәк үтеп керүе.

**Тема 2. Әбелмәних Каргалый (1782-1830)иҗаты. Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәнихкитабындагы хикәятләрнең эчтәлеге. Шагыйрьнең әдәбиятка алып кергән яңалыгы. Һибәтулла Салихов (1794-1867) иҗаты. Башлангыч һәм җитлек?кән чор иҗаты. Әсәрләрендә әхлак, тәрбия, шәхес һәм тирәлек мәсьәләре. Шәмсетдин Зәки (1821-1865). Тормыш юлы. Шәхес буларак үзенчәлекле яклары. Әсәрләренең сәнгатьчә эшләнеше. Баһавиның Бүз егет (1842) дастаны.**

устный опрос , примерные вопросы:

Ә.Каргалыйның Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних китабы. Баһавиның Бүз егет китабының Шәрыкъ далаларына тартымлыгы. Һ.Салиховның Тәндә җаным шигыре, аның иҗтимагый яңгыраш алуы. Ш.Зәки карашларының каршылыклыгы. Г.Кандалый иҗатын чорларга бүлү.Һибәтулла Салихов (1794-1867) иҗаты. Беренче мәрсияләре. Тел-стиль һәм идея-художество үзенчәлекләре. Шәмсетдин Зәки (1821-1865). Тормыш юлы. Иҗатында суфыйчылык мотивлары. Әсәр-ләренең сәнгатьчә эшләнеше. Баһавиның Бүз егет (1842) дастаны.

**Тема 3. Габделҗаббар Кандалый (1797- 1860). Тормыш юлы. Реаль тормыштан алынган татар хатын- кызларының матурлыгын сурәтләгән әсәрләре. Кереш.XIX йөзнең II яртысында (1861-1905) татарәдәбияты. Әдәбиятта мәгърифәтчелек реализмының формалашуы. Күренекле мәгърифәтчеләр һәм аларның эшчәнлеге. XIX йөзнең II яртысында татар поэзиясе. Поэзиягә мәгърфәтчелек идеяләренең тирән үтеп керүе. Дастан жанрының яңа биеклеккә күтәрелүе.**

письменная работа , примерные вопросы:

Габделҗаббар Кандалый (1797- 1860). Рисалаи-р-иршад, Кыйссаи Ибраһим Әдһәм поэмаларында борынгы татарәдәбияты мотивлары.XIX гасырның икенче яртысында төп иҗат методы буларак мәгърифәтчелек реализмының урнашуы. Язучыларның иҗат принциплары: милләтнең бүгенгесен һәм киләчәген кайгырту, аны бербөтен итеп карау һ.б.

**Тема 4. Мифтахетдин Акмулланың (1831-1895) тормыш һәм иҗат юлы, шәхесе. Гали Чокрыйның (1826-1889) тормышы, әдәби мирасы, мәрсияләре. Яков Емельяновның (1843-1898) тормыш юлы, әдәби мирасы. Әхмәт Уразаев-Кормаши (якынча 1855-1883).**

реферат , примерные темы:

Гали Чокрыйның (1826-1889) Шәмгыз-зыя әсәре. Мәдхе Казан, Фосуле әрбага җыентыклары. Хаҗнамә әсәре. Әдәбиятка алып кергән яңалыгы. Яков Емельяновның (1843-1898) тормышны реалистик детальләрдә сурәтләве. Әдипнең рус поэзиясенә мөрәҗәгать итүе. Поэзиясенең үзенчәлекле сыйфатлары: теленең халыкчанлыгы, гади, ачык булуы. Шагыйрьнең татар поэзиясендә тоткан урыны. Әхмәт Уразаев-Кормаши (якынча 1855-1883). Иҗатында романтик мәхәббәт сюжетына нигезләнгән дастан-кыйсса жанры үсеше. Кыйссаи Бүз егет, Кыйссаи Таһир илә Зөһрә әсәрләре һәм андагы сурәтләү чаралары.

**Тема 5. XIX йөз татар прозасы. Әдәбиятта проза жанрының активлашуы һәм моның сәбәпләре. Заһир Бигиевнең (1870-1902) тормышы һәм иҗат эшчәнлеге. Өлүф (меңнәр) яки гүзәл кыз Хәдичә романы. Мавәраэннәһердә сәяхәт(1893)әсәренеңязылу тарихы.**

тестирование , примерные вопросы:

XIX гасырның икенче яртысында төп иҗат методы буларак мәгърифәтчелек реализмының урнашуы. Язучыларның иҗат принциплары: милләтнең бүгенгесен һәм киләчәген кайгырту, аны бербөтен итеп карау һ.б. К.Насыйриның гыйльми мәгърифәтчелек һәм әдәби тәрҗемәчелек эшчәнлеге. Ярым журнал характерындагы еллык календарьлары. М.Акъегетнең Хисаметдин менла әсәренең жанры турында бүгенге фәндәге фикерләр. Ф.Кәрими әсәрләрендә уку-укыту проблемаларының урын алуы. Р.Фәхретдин әсәрләрендә гаилә әхлагы.

**Тема 6. XIX йөзнең соңгы чирегендә әдәбиятта драма төре барлыкка килү.Габрахман Ильясиның (1856-1895) тормышы, әдәби-мәдәни эшчәнлеге. ФатихХалиди (1850-1923) әдип һәм тәрҗемәче**

устный опрос , примерные вопросы:

XIX йөзнең соңгы чирегендә әдәбиятта драма төре барлыкка килү. Соңарып формалашу сәбәпләре. Беренче театр пьесаларының үз чоры өчен әһәмияте. Театр эшенә хәзерлекчараларытурында рус матбугаты. Милли театрның драматургия үсешендәге роле. Габрахман Ильясиның (1856-1895). Бичаракыз(1887)пьесасының сюжеты. Анда яңалыкһәм искелек көрәше. Хатын-кызазатлыгыпроблемасы. ФатихХалиди (1850-1923) әдип һәм тәрҗемәче Рәддебичаракыз(1881)әсәрендәхатын-кыз бәхете мәсьәләсе. Әдипнең башка әсәрләре: Морат Сәлимов, Мәхрүсәханым һ.б. Бәхетсезегет. Авторы билгесез Комедия Чистайда әсәре.

**Тема 7. Риза Фәхреддиннең (1859-1936) тормышы һәм мәдәни-гыйльми эшчәнлеге.**

реферат , примерные темы:

Риза Фәхреддиннең (1859-1936) белем-тәрбия, әхлак, тарих мәсьәләләренә караган һәм био-биографик характердагы күптомлык Асар (Эзләр) һ.б. хезмәтләре. Сәлимә, яки Гыйффәт (1898) повестенда әһәмиятле мәсьәләләр күтәрелү. Әсма, яки Гамәл вә җәза (1903) повесте. Күтәрелгән мәсьәләләрнең, геройлар язмышының мәгърифәтчелек идеологиясе кысаларында хәл ителүе. Р. Фәхреддин иҗатының әһәмияте.

**Тема 8. Фатих Кәриминең (1870-1937) тормыш юлы һәм иҗаты. Закир Һадинең (1863-1933)тормыш юлы һәм иҗаты. Шакир Мөхәммәдевнең (1865-1923) тормышы, күпкырлы иҗаты. Йомгак. XIX йөз татар әдәбиятының (II яртысы) сан һәм сыйфат ягыннан үзгәреш кичерүе, яңа әдәби төр һәм жанрлар барлыкка килү. Чынбарлыкны чагылдыруда яңа казанышларга ирешү. Әдәби тел үсеше. Бу чор әдәбиятының татар әдәбияты тарихында тоткан урыны.**

письменная работа , примерные вопросы:

Мәгърифәтчелек прозасы формалашу. Кысалы кыйсса турында төшенчә. Тәрҗемә эшенең киңәюе (К.Насыйри, В. Радлов һ.б. эшчәнлеге). МусаАкъегетзадәнең (1864-1923) тормыш һәм иҗат юлы. Хисаметдин менла(1886) әсәре. Аның жанры (повесть-роман) турында бүгенге фәндәге карашлар. Күтәрелгән төп мәсьәләләр: шәхес иреге һәм милләт мәнфәгате, гаилә тәрбиясе һәм мәдрәсәдә укыту; халыкчанлык идеясе. Романныңкомпозициясеһәм сюжеты. Татар әдәбиятындаберенчереалистик роман буларакәһәмияте. Заһир Бигиевнең (1870-1902) Зур гөнаһлар (Гөнаһе кәбаир, (1890) романы. Әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше. Мавәраэннәһердә сәяхәт(1893)әсәренең язылу тарихы. Сәяхәт-намәдәиҗтимагый, мәдәни, милли, дини, сәяси, әхлакый мәсьәләләрнең куелышы. Әлегәчә табылмаган әсәрләре.

**Тема 9. Кереш. XXйөз башы әдәбиятының үсеш баскычлары. Проза**

письменная работа , примерные вопросы:

XX йөз башы әдәбияты тарихында проза үсешенең ике баскычы: 1) 1885-1905 еллар; 2)унынчы еллар прозасы. Г.Исхакый - прозаик, драматург, публицист. Ф.Әмирхан иҗатындагы сатира, аналитик психологизм, татар зыялы яшьләр образы. Журналистлык эшчәнлеге. Ш.Камал хикәяләр атасы, иҗатындагы психологизм. Г.Ибраһимов иҗатының чорларга бүленеше. М.Гафури прозасында гади халык тормышы. Г.Исхакый иҗатын чорларга бүлү. Ф.Әмирхан сатирасы. Ш.Камал хикәяләрендә тормыш гаделсезлеге. Г.Ибраһимовның унынчы еллар иҗатында яңа сыйфат үзгәрешләре: Яз башы(1910), Диңгездә(1911), һ.б. хикәяләре. Әдипнең күләмле әсәрләре. М.Гафури әсәрләрендәге социаль каршылык.

**Тема 10. XX йөз башында поэзия. XX йөз башында драматургия**

тестирование , примерные вопросы:

1905 ел революциясенең поэзиягә йогынтысы. Мәгърифәтчелек идеяләренең гражданлык хисләре белән үрелеп бирелүе. Г.Тукайның тормыш юлы; башлангыч чор иҗаты. Казан чоры иҗаты. С.Рәмиев романтик шагыйрь. 1908 еллар иҗатында яңа сыйфат үзгәрешләре. Дәрдемәнднең фәлсәфи лирикасы, шигырьләрендәге мәгънәви тирәнлек. Н.Думави шигырьләрендә экспрессионистик сурәтлелек. Ш.Бабич поэзиясендә халык һәм шагыйрь, милләт язмышы. Тукайның гражданлык лирикасы, социаль мотивлар (Мужик йокысы, Милләт); иҗатының тематик киңлеге. Дәрдемәнд иҗатында яшәү һәм үлем, гомер агышы, билгесезлек турында уйланулар. Ш.Бабич иҗатында юмор һәм сатира; шигъриятендә лирик герой, үзенчәлекләре. Беренче драма һәм комедияләрдә мәгърифәтчелек әдәбияты идеяларенең чагылышы. Драматургия үсешенә милли профессиональ театрның барлыкка килүенең йогынтысы. Комедия жанрының активлашуы. Сатирик комедия, водевиль кебек яңа формалар барлыкка килү. Г.Камал әсәрләре. М.Фәйзи, Галиябану.

**Тема 11. 1917-1940 еллар әдәбияты.Г.Ибраһимов (1887-1938). Тормыш юлы һәм иҗаты.**

устный опрос , примерные вопросы:

1917елгы октябрь инкыйлабы, гражданнар сугышы. Бу чор әдәбиятының сәнгатьчә үзенчәлекләре. Шигъриятнең активлыгы. Кешелеклелек һәм сыйнфыйлык төшенчәләренең үзара мөнәсәбәте. Бу күренешнең дәүләт идеологиясе булып әверелүе, әдәбиятка көчләп тагылуы һәм шуның нәтиҗәсе буларак, сүз сәнгатенең табигый үсеше тоткарлануы. Г.Ибраһимовның тормышы, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге. 1917елдан соңгы әсәрләрендә сыйнфыйлык. Безнең көннәр романында XX йөз башы татар тормышының эпик колачлылыгы. Тирән тамырлар, Кызыл чәчәкләр әсәрләрендәге сыйнфый көрәш. Әсәрләрендәге ике планлылык. Казакъ кызы романында Россия сәясәтенең казах тормышына йогынтысын, шуның нәтиҗәсе буларак күчмә кабиләләр арасындагы традицияләрнең җимерелүен күрсәтү. Мәҗит Гафури. 1917 нче еллар инкыйлабыннан соң иҗтимагый-эстетик карашларында үзгәрешләр. Чор вакыйгаларын иҗатында чагылдырып баруы. Прозада үткәннәргә мөрәҗәгать. Иҗатында тема байлыгы. Драматургия һәм татар опера сәнгате үсешенә керткән өлеше. Кара йөзләр повестында психологик анализ остасы буларак ачылуы. Повестьта яшьләрнең фаҗигасен китереп чыгарган сәбәпләр.Г.Ибраһимов, М.Гафури әсәрләре Гражданнар сугышы һәм әдәбият. Вульгар социологизм. Илне индустрияләштерү, дингә каршы көрәш, яшьләрнең яңа тормыш өчен көрәш алып баруларын сурәтләүнең катгый таләп итеп куелуы.

**Тема 12. Һ.Такташ, Ш.Усманов, Ф.Бурнаш иҗаты.**

устный опрос , примерные вопросы:

Әсәрләрендәге романтизм, үз шигъри мәктәбен туды Һ.Такташ иҗатын чорларга бүлеп карау руы. Газраилләр, Күктән сөрелгәннәр, Җир уллары трагедиясендә иҗтимагый чынбарлыкны символик сурәтләр аша тасвирлавы, тормыштагы гаделсезлекләр белән килешмәвенең чагылуы. Рәсми сәясәт куйган таләпләрнең шагыйрь иҗатына булган тискәре йогынтысы. Иҗатының икенче чоры. Такташ үлде, Син дә үл инде шигырьләренең манифестик рухы. Гасырлар һәм минутлар поэмасында Ленин образы. Мокамай, Алсу, Сыркыды авылы әсәрләрендә кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре. Язучы, драматург һәм җәмгыять эшлеклесе Ш.Усмановның тормыш һәм көрәш юлы. Революциягә һәм әдәбиятка мөнәсәбәте. Канлы көннәрдә, Ил кызы, Легион юлы әсәрләрендә гражданнар сугышы һәм кеше язмышы мәсьәләләре. Ф.Бурнашның тормыш юлы, иҗтимагый - сәяси эшчәнлеге. Поэмалар шагыйре буларак танылуы һәм аларның тематикасы. Иҗатының романтик рухы. Камали карт,Ялгыз Ярулла комедияләрендә яңалык тарафдары буларак чыгыш ясавы. Һ.Такташ, Ш.Усманов, Ф.Бурнаш әсәрләре. Һ.Такташ иҗатында романтизм. Иҗатының икенче чоры, аның үзенчәлекләре. Драматург, шагыйрь Ф.Бурнаш. Поэмаларының тематикасы һәм сәнгатьчә эшләнеше. Ш.Усманов язучы, драматург һәм җәмәгать эшлеклесе. Канлы көннәрдә, Легион юлы, Ил кызы, Краском мәхәббәте әсәрләрендә гражданнар сугышы һәм кеше язмышы мәсьәләсе.

**Тема 13. К.Тинчурин, Ш.Камал иҗаты.**

письменная работа , примерные вопросы:

К.Тинчуринның комедия остасы буларак танылуы. Октябрь инкыйлабыннан соң татар профессиональ театрын үстерүдәге өлеше. Американ,Җилкәнсезләр, Хикмәтле доклад комедияләре. Зәңгәр шәл, Казан сөлгесе, Кандыр буе, Ил музыкаль драмалары, аларның проблематикасы, сәнгатьчә эшләнеше. Иҗатына вульгар социологизмның тәэсире. Ш.Камалның Матур туганда романы. Әдипнең матурлык төшенчәсен сыйнфыйлык аша аңларга омтылышы. Акчарлакларның дәвамы буларак Таң атканда романы. Рәсми идеология тәэсире нәтиҗәсендә әсәрнең йомшак булуы. Сәхнә әсәрләренең проблематикасы.

**Тема 14. Т.Гыйззәт, К.Нәҗми иҗаты.**

реферат , примерные темы:

Нәҗми (1901-1957) иҗаты Т.Гыйззәт иҗатының үсеш этаплары. Пьесаларында инкыйлабка кадәрге татар авылы тормышының бирелеше, татар крестьяннары хәлен тарихи дәвамлылыкта күрсәтү. Ташкыннар трилогиясендә Биктимер һәм Аюхановлар гаиләсе аша сыйнфый каршылыкны күрсәтү. Кави Нәҗминең ортадоксаль пролетариат әдәбияты тарафдары булып формалашуы. Кояшлы яңгыр, Якты сукмак, Яр буенда учаклар повестьларында чынбарлыкның берьяклы сурәтләнеше. Т.Гыйззәтнең Ташкыннар трилогиясе. Өлешләрнең аерым һәм трилогиянең тулаем проблематикасы. К.Нәҗминең Кояшлы яңгыр, Якты сукмак әсәрләрендә чынбарлыкның берьяклы сурәтләүе.

**Тема 15. Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты.**

устный опрос , примерные вопросы:

Бөек Ватан сугышы елларында татар халкының фронтта һәм тылда күрсәткән батырлыгы. Сугыш елларында әдәбиятның роле, аның алдына куелган бурычлар. Сүз сәнгатенең кешедә матурлыкка омтылыш тәрбиялисе урында чиксез нәфрәт уятырга хезмәт итә башлавы. Әдәби төрләрдән поэзиянең активлашуы. Ф.Кәримнең (1909-1945) 1922-1927еллардагы башлангыч чор иҗатында романтика. Сталин лагерьларындагы (1937-1941) иҗаты, сугыш чоры лирикасында кырыс чынбарлык күренешләре, яшәү һәм үлем фәлсәфәсе турында уйланулары. Муса Җәлилнең (1906-1944) тормышы һәм иҗаты. Гражданнар сугышы елларындагы башлангыч чор иҗатында романтика. 30-нчы еллар ахырында лиризмның тирәнәюе. Шагыйрьнең сугыш чоры иҗаты. Фронт шигырьләренең тематикасы һәм поэтикасы. Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты. М.Җәлил, Ф.Кәрим иҗаты. М.Җәлилнең әсрлек шартларындагы шигъри һәм гражданлык батырлыгы. Җырларым, Ышанма, Кичер илем, Кошчык, Ирек әсәрләрендә автор образы, аның рухи көче гәүдәләнү. Ф.Кәримнең проза әсәрләре.

**Тема 16. Ш.Маннур, Х.Туфан иҗаты.**

письменная работа , примерные вопросы:

Хәсән Туфан (1900-1981): гүзәл гамьле иҗат. Ш.Маннурның беренче шигъри тәҗрибәләре. Хезмәт пафосын һәм социалистик ярышны гәүдәләндергән Колчеданлы таулар итәгендә, Чуен ташкыннар, Бетончылар җыры поэмалары. Ватан сугышы чоры лирикасында яшәү, тормыш, сөю турында уйланулар. Муса романында герой шагыйрь образын беренчеләрдән булып тасвирлавы. Х.Туфанның катлаулы һәм фаҗигале тормыш юлы. Башлангыч чор иҗатындагы Зәңгәр бүре, Еллар чигәсендә, Урал эскизлары, Ике чор арасында, Башлана башлады, Бибиевлар поэмаларында искелек белән яңалык көрәшен бирү. Шагыйрьнең тоткынлык лирикасының фәлсәфи эчтәлеге, тематик киңлеге ( Үзеңә бүләе итәсе иде, Агыла да болыт агыла һ.б.). Сурәтле фикерләвендә үзгәрешләр, сугыш темасына тоткын шагыйрь карашы (Гөлләр инде яфрак яралар, Моабитны күрдем төшемдә һ.б.). Ш.Маннур, Х.Туфан әсәрләре Ш.Маннурның Җир-әнкәнең сылу кызы (1953-1956) шигъри повестенда мотивлар. Муса (1964) романында герой шагыйрь образы. Х.Туфанның 60еллар иҗатында иҗтимагый фәлсәфи лириканың көчәюе. ( Еллар, ахры, байтак үткәннәр, Сәлам сиңа, тормыш, Кармәт истәлекләре һ.б.).

**Тема 17. И.Гази, Ф.Хөсни иҗаты. Г.Әпсәләмов, М.Әмир иҗаты. Ә.Еники, Г.Бәширов иҗаты.**

тестирование , примерные вопросы:


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Сугыштан соңгы татар прозасында тематиканың киңәюе, зур күләмле, киң колачлы әсәрләр иҗат ителүе. И.Газинең беренче иҗат тәҗрибәләре. Бөек Ватан сугышы чоры иҗатында үзгәрешләр, персонажларның эчке дөньяларын тасвирлауга игътибар арту (Алар өчәү иде, Якташһ.б.). Г.Әпсәләмовның әдәби юнәлешен билгеләүдә Бөек Ватан сугышының роле. Чынбарлык биргән каһарманнарны әдәби образлар дәрәҗәсенә күтәргән күләмле романнары (Газинур, Мәңгелек кеше). Бер гаиләнең тарихи эволюциясе аша эшчеләр тормышын сурәтләгән Сүнмәс утлар романы. М.Әмирнең башлангыч чор иҗаты (1928-1930). Безнең авыл кешесе, Агыйдел әсәрләренең идея-тематик эчтәлеге, яшьләр образы аша бирелгән заман каршылыгы. М.Әмир драматургиясендә сугыш темасы. Онытылмас еллар трилогиясендә татар иҗтимагый тормышының эпик колач белән сурәтләнүе. Язучы күтәргән милли мәсьәләләр. Ф.Хөсни хикәяләр остасы. Йөзек кашы повестындагы төп герой Айдарның үзенчәлекле характеры. Утызынчы ел романы. Шәхси язмышларны социаль вакыйгалар белән бәйләп, яшерен хакыйкатьне бирергә омтылышы. Җәяүле кеше сукмагында кеше язмышын тормыш катлаулылыгында тасвирлавы.

**Тема 18. Кереш. Рун-уйгур язулы истәлекләр. Гарәп язулы истәлекләр. Болгар чоры әдәбияты. Алтын Урда чоры әдәбияты. Казан ханлыгы чоры әдәбияты. XV-XVI йөзләрдә иҗат иткән әдипләр.**

устный опрос , примерные вопросы:

М. Кашгарый, Й. Баласагунлы, Ә. Йүгнәки, ә. Ясәви, С. Бакырганый иҗатлары турында кыскача белешмә. Кол Гали. Кыйссаи Йосыф поэмасы. Рабгузый, Харәзми, М. Болгари, Ә. Үргәнчи әсәрләре. Х. Кятиб. Котб иҗаты. С. Сараиның тәрҗемәи хәле һәм иҗаты. Өмми Камал, Мөхәммәт Әмин, Кол Шәриф, Шәрифи иҗатлары турында кыскача белешмә. Мөхәммәдъярның тәрҗемәй хәле, иҗаты.

**Тема 19. XVII йөз әдәбиятына күзәтү. XVIII йөз әдәбияты. Кереш. Курсның максаты, бурычлары, татар әдәбияты тарихында тоткан урыны, башка предметлар белән бәйләнеше. XIX йөзнең 1 яртысында татар поэзиясе. XIX йөзнең II яртысында (1861-1905) татар әдәбияты. Йомгак.**

письменная работа , примерные вопросы:

М. Колый иҗаты. Габдессәлам, Г. Мөслим, Әхмәдбик, Т. Ялчыгол. Г. Утыз Имәни. Тәрҗемәи хәле. Иҗатына гомуми күзәтү. XIX йөзнең 1 яртысында әдәбиятның нигездә шигъри характерда үсеше. Ә.Каргалый иҗатында дини суфыйчылык мотивларының дөньяви башлангыч белән үрелеп үсүе. Гомәр Мөхәммәт улы әсәрләренең татар әдәбиятына алып килгән яңалыгы. Һ.Салихов мәрсияләре. Ш.Зәкинең әхлакый сафлыкны идея итеп үзгәртүе. Г.Кандалыйның мәхәббәт җырчысы буларак алып килгән яңалыгы. К.Насыйри мәгърифәтче язучы, энциклопедик галим. XIX йөзнең 2 яртысында поэзия. Поэзиянең чынбарлыкка, халыкны борчыган мәсьәләләргә якынлыгы. Мәгърифәтчелек идеяләренең тормыштагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә поэзиягә торган саен тирәнрәк үтеп керүе.

**Тема 20. Кереш лекция. 1960-1985 нче еллар татар әдәбиятына гомуми күзәтү.**

реферат , примерные темы:

Татар әдәбиятының элекке чорлардан килгән традицияләрен жанрлар, тема - проблемалар һәм әдәби-сәнгать чаралары ягыннан дәвам итү. Илдәге сәяси-иҗтимагый үзгәрешләргә бәйле яңарыш-демократик карашларның активлашуы; дөньяга карашның идеологик бәйлелектән арына баруы; шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләрендә конкрет кеше мәнфәгатен алга куеп иҗат итү. Жанрлар төрлелеге, фән һәм сәнгать үсешенең тәэсире, үзара йогынты ясаулары, бу чорны тарих үсешенең бер этабы дип бәяләү. Яңа традицияләр формалашу.

**Тема 21. Татар прозасына гомуми күзәтү.**

устный опрос , примерные вопросы:


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Бөек Ватан сугышына багышланган әсәрләрдә татар ир-егетләренең яу кырындагы язмышларын киң, тулы һәм конкрет итеп тасвирлау. Ә.Еникиның Без дә солдатлар идек(1971), Х.Камаловның һәркемнең гомере бер генә(1975), Безне өйдә көтәләр(1985), М.Мәһдиевнең Кеше китә - җыры кала (1978), М.Юнысның Шәмдәлләрдә генә утлар яна(1979) әсәрләре. Татарстанда, илдә барган үзгәрешләрне - нефть табылу, Камаз һәм яңа шәһәрләр төзелү Һ.б.- тасвирлауны максат итеп кую. Г.Ахуном Хәзинә(1962)), Хуҗалар(1968), Э.Касыймов "Томан аша"(1968). "һаваларда тургай"(1973), Ә.Баянов "Ут һәм су"(1971), Ш.Бикчурин "Каты токым"(1972) романнары.Тарих һәм хәзерге заман белән бәйләнгән темалар һәм мәсьәләләр.Татар халкының үткәндәге иҗтимагый-рухи тормышын, тарихым яктыртуда Н.Фәтгах Итил суы ака торур(1969), Сызгыра торган уклар (1982)), М.Хәбибуллин Кубрат хан(1984) һ.б. романнарының әһәмияте.

**Тема 22. Гомәр Бәширов, Аяз Гыйләҗев, А.Расих иҗатларына гомуми күзәтү.**

письменная работа , примерные вопросы:

Гомәр Бәширов (1901-1999) Г.Бәшировның озын һәм катлаулы тормышы, иҗат юлы. Беренче иҗат тәҗрибәләре, журналист һәм язучы буларак формалашуы. Беренче хикәяләрендә (Канлы бармаклар, Соңгы сугыш) авылдагы сыйнфый көрәш чагылышы. Сиваш повестендә гражданнар сугышы вакыйгаларын татар сугышчылары образлары аша ачарга омтылыш. Язучы иҗатында сугыш темасының үзенчәлекле чагылышы. Бу еллардагы авыл тормышын, халыкның фидакарь хезмәтен чагылдырган Намус романы, әсәрдә сугыш елларныда хатын кызларның авыр хезмәтенең, илгә тугрылыгының чагылышы. Әдәби тәнкыйтьнең әсәргә үз чорындагы һәм хәзерге бәясе. Г.Бәширов иҗатында авыл темасының төрле яклы чагылышы. Туган ягым яшел бишек әсәрендә туган җир, туган туфракка мәхәббәтнең автобиографик чагылышы, халык тормышының, гореф-гадәтләрнең, күркәм традицияләренең язучының үз кичерешләре аша гәүдәләнеше үзенчәлеге.АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ (1928-1992) Әдипнең гыйбрәтле һәм катлаулы тормыш юлы турында белешмә, Беренче әсәрләреннән үк кырыс реализм, үзенчәлекле сурәтләү алымнары. Өч аршын җир(1962), Зәй энҗеләре(1963), Үги ВН| яфраклары(1964), Язгы карваннар(1972), Мәхәббәт һәм нәфр.м турында хикәят(1973) әсәрләрендә шәхеснең катлаулы рухи дөньясын образлы итеп бирүе, әдәп-әхлак мәсьәләләрен фәлсәфи яссылым.I гәүдәләндерүгә омтылышы. Өч аршын җир повестының ӘД90М хәрәкәткә алып килгән яңалыгы.Җомга көн кич белән(1979) повестының сюжет һәм композиция үзенчәлекләре. Балта кем кулында(1989), Йәгез, бер дога(1993) романнарында җәмгыятьтәге гаделсезлекләргә һәм шәхес ирМН чикләүләргә, һәртөрле тыюларга каршы юнәлдерелгән пафосның әдәби-публицистик планда гәүдәләнеше А. РАСИХ (1916-1996) Тормышы һәм иҗат юлы. Әдәбияттагы тәүге адымнары. Сатирик хикәяләр белән танылуы. Сугыш чоры хикәяләрендә кеше рухының олылыгына, ныклыгына, матурлыгына дан җырлау."Дошман тылында"(1943), "Сагынылган мәхәббәт"(1944) хикәяләре, Бәхет орлыклары(1945) мажаралы повесте. Дустым Мансур(1955), Язгы авазлар(1963), Ике буйдак(1965), Сынау(1978), Каһарманнар юлы(1965), Ямашев(1968-1981) романнары әдипнең иҗат активлыгын һәм гематик колачын чагылдырган әсәрләр. Әдипнең мәгънәле фикер, рациональлек, фәннилеккә нигезләнгән үзенчәлекле стиле.Елларны чигерсәм(1990) исемле, тәмамланып җитмәгән автобиографик әсәре. Шуңа кергән Ишан оныгы повестенең әдәби эшләнеше һәм анда куелган иҗтимагый проблемалар.

**Тема 23. Татар әдәбиятында тарихи тема. Нурихан Фәттахов, М.Хабибуллин**

письменная работа , примерные вопросы:

М. Хәбибуллин (1927). Язучының тормышы һәм эшчәнлеге. Төрле һөнәр ияләренең рухи-әхлакый йөзләрен ачуга багышланган Икмәк кадере, Тау белән тау очрашмаса да(1970); сугыштан соңгы авыр авыл тормышын сурәтләгән Чоңгыллар(1973), Сулар үргә акса да (1982) повесть һәм романнары... М.Хәбибуллин романнарында гомумкешелек һәм конкрет-тарихи моментлар. Татар трагедиясе һәм дәүләтчелек турындагы якты сагыш темасы. Әсәрләрдә гуманизм төшенчәсенең Татар иле хыяллары белән бәйләнеше. Кубрат хан романында вакыт проблемасы. Кубрат хан, Илчегә үлем юк, Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный әсәрләрендә акыллы, гадел хан, патша, аның халкының киләчәге, дәүләтенең бөтенлеге, иминлеге өчен җаваплылыгы мәсьәләсе, төрки дәүләтләрнең бердәмлеге, бөтенлеге, тынычлыгы өчен көрәшүче гуманист герой образы. М.Хәбибуллин Романнарының тарихи тематикасы һәм аларның бүгенге тормыш белән бәйләнеше. Н. Фәттах (1928-2005) Күренекле прозаик, татар әдәбиятында тарихи роман жанрына нигез салучыларның берсе, драматург, публицист Нурихан Фәттахның гормыш юлы һәм иҗат этаплары.Сезнеңчә ничек??(1956), Бала күңеле далада(1962), Мөдир Сажидә(1968) әсәрләрендә заман сулышының чагылышы. Кырык дүртнең май аенда(1965), Кичү(1956-1990) әсәрләрендә заман, шәхес һәм җәмгыять проблемаларының үткен куелышы. Татар халкының ерак үткәнен тасвирлаган Итил суы ака торур(1969), Сызгыра торган уклар(1977-1985), романнарында Кол Гали(1972) трагедиясендә күтәрелгән мәсьәләләрнең мөһимлеге, әсәрләрнең әдәби эшләнеше.

**Тема 24. Татар әдәбиятында авыл прозасы. М.Мәһдиев, Р.Төхфәтуллин, Э. Еники иҗатлары.**

устный опрос , примерные вопросы:

МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ (1930-1995) Күренекле шәхес, язучы, әдәбият галиме, публицист, педагог Мөхәммәт Мәһдиевның тормышы һәм иҗат юлы. Әдәбиятта беренче адымнары."Без - кырык беренче ел балалары"(1968) повестеның, Фронтовиклар"(1972) романының тематик һәм эстетик яңалыклары, педагоглар һәм яшьләр образларының үзенчәлекле яктыртылышы.Авыл һәм аның кешеләре тормышының сугышка кадәр, сугыш чорында һәм сугыштан соңгы елларда гәүдәләнеше ("Каз канатлары"(1975), "Кеше китә - җыры кала"(1978), "Исәнме, Кәшфи абый"(1982) һ.б.).Төрле жанр билгеләрен бергә кушкан, яңа типтагы, эссе рәвешендәге әсәрләрне иҗат итү ( ("Торналар төшкән җирдә"(1979), Бәхилләшү"(1987).) Әсәрләрдә автор образының роле. Ә.ЕНИКИ (1909-2000) Тормыш һәм иҗат юлы. Әдәбиятка килү юлындагы беренче тәҗрибәләре. Ватан сугышы чоры хикәяләрендә образлармы гәүдәләндерүдә психологизм һәм лиризм. Сугыш чынбарлыгын кеше рухында, табигате-холкында драматик һәм фаҗигале гәүдәләндерелгән Бала(1941), Ана һәм кыз(1942), Бер генә сәгатькә(1942), Тауларга карап(1948), Кем җырлады(1956) һ.б. хикәяләре. Тормыш күренешләрен һәм кеше характерларын сурәтләүдл психологик тирәнлеккә омтылу, төрле катлаулы мөнәсәбәтләрне реалистик рухта яктырту (Туган туфрак(1959), Матурлык( 1964). Шаяру(1955), Җиз кыңгырау, Тынычлану (1978) һ.б.). Саз чәчәге(1955), Рәшә(1962), Гөләндәм туташ хатирәсе(1975) әсәрләрендә геройлар күңелен ачу осталыгы, фәлсәфи фикерләрнең тирәнлеге, стиль төсмерләренең байлыгы.Истәлекләр аша иҗтимагый-социаль хәрәкәтне чагылдыр! им Соңгы китап(1985) әсәренең әһәмияте. Р. ТӨХФӘТУЛЛИН (1924-1994) татар прозасындагы лирик агымның күренекле вәкиле. Тормыш күренешләрен реалистик һәм романтик сурәтләрнең үрелеше ярдәмендә чагылдырган үзенчәлекле стиле.

**Тема 25. 1960-1985 нче еллар татар поэзиясенә гомуми күзәтү.**

реферат , примерные темы:

1960-1985 елллларда поэзия. Поэзиядә кеше шәхесенә игътибар арту. Лирик агымның көчәюе Өлкән буын шагыйрьләренең иҗат активлыклары үсү. Х.Туфан, С.Хәким, Ш.Маннур, Н.Арыслан, Ә.Давыдов, С.Баттал һ.б. иҗатында үткән белән бүгенгене бәйләү, сугыш темасын яңарту, туган авылга, җиргә мәхәббәт, тормышка соклану кебек мотивлар. И.Юзеев, Ш.Галиев, С.Сөләйманова Х.Камал, Г.Афзал, Ә.Баянов иҗатларының үзенчәлекләре. Поэзиягә яна буын шагыйрьләре килү (Р.Фәйзуллин, Р.Миңнуллин, Р.Харис, Р.Мингалим, Зөлфә I, М.Әгъләмов, Р.Гаташ һ.б.). Шигъриятктә яңа образлар алып килүләре, иҗатларында хис һәм фикер байлыгы, әдәби кыюлык һәм фәлсәфи тирәнлек.. Поэтик жанрлар һәм аларның үсешендәге яңалыклар Традицияләр һәм новаторлык мәсьәләләре.

**Тема 26. 1960-1985 нче еллар татар драматургиясенә гомуми күзәтү**

письменная работа , примерные вопросы:

1965-85 еллар драматургиясендә сыйфат үзгәрешләре.Драматургиягә килгән бер төркем авторлар - Хәй Вахит, Шәриф Хөсәенов, Туфан Миңнуллин, Ильдар Юзеев, Аяз Гыйләҗев -әсәрләренең татар театрын үстерүдәге роле, әһәмияте. Аларның тирән иҗтимагый-фәлсәфи, җитди әхлакый проблемаларны күтәргән, заман героеның катлаулы психологик кичерешләрен чагылдырылган пьесалар тудырулары.1960 еллар драматургиясендә комедия жанрының өстенлек итүе. Ю.Әминов Сатучылар(1961),),"Өти балак"(1964), "Уҗым бозавы" (1966), Ш.Хөсәеновның Зөбәйдә - адәм баласы (1961), Х. Вахитның Күк капусы ачылса" (1967) һ.б. комедияләрдә тормышның җитди проблемаларын анализлауга омтылу.1970 еллар драматургиясендә халыкчанлыкка игътибар арту. А.Яхин, А.Гыйләҗевнең Шамил Усманов(1967), А.Гыйләҗевныц Көзге ачы җилләрдә(1964), "Сары чәчәк ата көнбагыш"(1974), Н.Фәттахның Кол Гали(1972), Т.Миңнуллинның Канкай улы Бәхтияр( 1974),"Моңлы бер җыр"(1981) һ.б. тарихны шәхес аша бирү.Әсәрләрдә Шәхеснең әхлакый дөньясы, милли гореф-гадәтләр югалу проблемасы, кешелек сыйфатларының кими баруы, мал туплау, түрә булу теләге белән җинаятьләр кылу тема-проблемаларын яктырткан Ш.Хөсәеновның "Әни килде"(1965), Т.Миңнуллин Әниләр һәм бәбиләр (1984), Без китәбез, сез каласыз (1987), Ат карагы (1989), Илгизәр + Вера(1991) һ.б. драмалары.Шагыйрь-драматург И.Юзеевның заман һәм халык, тарихи язмышлар, нәсел-нәсәбә, гореф-гадәтләр, мәхәббәт һәм гаилә кебек тема-проблемаларны күтәреп язган пьесалары.

**Тема 27. С.Сөләйманова, И. Юзеев тормыш һәм иҗат эшчәнлегенә гомуми күзәтү.**

устный опрос , примерные вопросы:

С.СӨЛӘЙМАНОВА (1926-1980). Тормыш юлы һәм иҗади үсеше турында мәгьлүмәтләр.Тормыишы тирән тоемлавы. Заман темалары, иҗтимагый социаль күренешләрне үч шәхси кичерешләре, биографиясе белән тыгыз бәйләнештә бирелеше .Шагыйрә иҗатында мәхәббәт лирикасының зур урын алуы.. И. ЮЗЕЕВ (1933-2004) Татар поэзиясенең күренекле вәкиле Илдар Юзеевның тормыш һәм иҗат юлы. Таныш моңнар(1955) поэмасы һәм аның лирик геройлары белән алып килгән яңалыгы. Үз геройларын Галәм, Җир кешесе дип, ә яшәү мәгънәсе - мәхәббәттә, гадел хезмәттә дип исбат итүе.Әнкәй(1959), Фәрит-Фәридә(1958), Өчәү чыктык ерак юлга(1964-1965), Өзелмәс кыллар(1977), Мәхәббәт китабы(1979) кебек лирик, драматик поэмаларында хис һәм фикер гармониясе, I абигыйлеккә омтылу, сурәтләрдәге эчке моң. ихласлылык, кешелеклелек сыйфатларының табигый гәүдәләнеше. Кеше рухының бөеклегенә дан җырлау, ялганга, шәфкатьсезлеккә каршы нәфрәт хисләренең чагылышы.

**Тема 28. Татар поэзиясендә юмор. Г.Афзал, Ш.Галиев иҗатларына гомуми күзәтү**

устный опрос , примерные вопросы:

Г. АФЗАЛ (1921-2003) Г. Афзалның тормыш һәм иҗат юлы. 1955 елда беренче шигырьләре белән олы әдәбиятка юл яруы "Кар сулары" ( 1957 ), "Вөҗдан сүзе" (1958), "Кояшлы яз" (1961), исемле шигырь җыентыклары. Алтмышынчы елларда нечкә хисле лирик буларак танылуы, теленең афоризмнарга бай булуы Җитмешенче елларда үткен телле, кыю сатирик буларак дан алуы "Ышаныгыз" (1971), "Кышкы озын кичләрдә"(1975), "Айлы кичләр" (1977) исемле җынтыкларның дөнья күрүе. Сиксәненче-туксанынчы елларда иҗатында тарихилык рухы, халыкның үсешен чикләп килгән тоталитар режимны фаш итүе, милли үзаңны уятып торучы фәлсәфи әхлакый агымга игътибар итүе. "Шундый-шундый эшләр" ( 1988 ). "Август йолдызлары" (1994), "Гомер кичүләре? исемле шигъри җыентыклары.Проза өлкәсендәге тәҗрибәләре.Әсәрләренең рус, башкорт һ.б. халыклар телләренә тәрҗемо ителүе. Күп шигырьләренең татар телендә популяр җырларга әверелүе Иҗатының соңгы елларында халыкчан, милли тойгыларының аеруча җанлануы. Ш. ГАЛИЕВ (1928) Тормышы һәм иҗат юлы турында мәгълүматлар. Әдәбиятта беренче адымнары. Илленче еллар башында язылган беренче җыентыклары - Яңа койләр"(1954), Кичке утлар(1956), Әткәйгә хат (1958). Туган авылы, аның кешеләре, табигате, күңелдәге сугыш яралары, мәхәббәт турында язылган шигырьләре.Алтмышынчы-җитмешенче елларда хисләрнең табигыйлеге, халыкчан бизәкләр, фикерләрнең фәлсәфи үткенлеге, шулай ук форма олкәсендәге камиллек һәм юмор белән аерылып торган шигырь җыентыклары барлыкка килү.

**Тема 29. Ш.Хөсәенов, Х.Вахит. Н.Исәнбәт тормыш һәм иҗат эшчәнлеге**

тестирование , примерные вопросы:

Ш. ХӨСӘЕНОВ (1929-1999) иҗаты. Язучы драматур буларак иң беренче Профессор кияве( 1952) комедиясе белән танылуы. Зөбәйдә адәм баласы (1961)исемле трагикомедиянең үзенең фикри эчтәлеге һәм сәнгати эшләнеше ягыннан гына түгел, жанр төрлелеге ягыннан да зур кызыксыну уятуы. Әсәрдә трагик белән комиклыкның бергә үрелеп бирүе. Адәм баласы турындагы фәлсәфи караш әсәрнең төп геройлары ярдәмендә расланәуы.Әсәрдә сатирик образлар: Габдрахман, Сәмигулла образлары. Җәүһәрия трагедиясенең күп хатын-кызлар язмышында кабатланывы. Татар драматургиясенең алтын хәзинәләренә кергкән әсәр булуы. Әни килде(1968) драмасы.

**Тема 30. Ю.Әминев, Р.Хәмид тормыш һәм иҗат эшчәнлеге**

письменная работа , примерные вопросы:

Әминов (1921-1982) иҗаты Тамырлар(1961), Гөлчәчәк (1963), Минем җинаятем(1971), Гөлҗәннәтнең җәннәте (1973), Кан кардәшләр, Сөймим дисәң дә... (1976) һ.б. әсәрләре, Кошның да үз канаты була (1967), Өти балак (1968) драмаларында, Сафура бураннары (1974) кебек комедияләрендә дә кешенең рухи халәтен тасвирлауга нык игътибар бирелү. Драматургның Әлмәт чорындагы әдәби иҗаты тематик яктан да төрләнү-киңәю кичерә: аның әсәрләренә шәһәр тормышы, нефтьчеләр, завод эшчеләре образлары килеп керү.Р.ХӘМИД (1941) Драматург буларак формалашу шартлары, фәлсәфи-эстетик карашлары. Тарихи-сәяси вакыйгалар нәтиҗәсендә татар авылының төрле төркемнәргә аерылуын күрсәткән Китәм инде(1983) драмасы, анда шәхси фаҗиганең сәбәпләрен ачу. Геройлардагы кичерешләр тирәнлеген бирүдә аларның үзара туганлык мөнәсәбәтендә булуларының әһәмиятле рольуйнавы. Аталар һәм балалар арасында барган конфликтның Каен җиле(1982) әсәрендә үзенчәлекле дәвам ителүе. Төп герой Илсурның тормыш принциплары, аңа авторның мөнәсәбәте. Каен образының эчтәлеге.Бер генә каһарман сөйләменә корылган Олы юлның тузаны монодрамасы. Нәүхәбәр карчык образын Хәтер категориясе аша ачу. Бүгенге ахлаксызлык, кешелексезлек, миһербансызлыкның сәбәпләрен үткәннән эзләү. Нәүхәбәр карчык образын ачу ягыннан сандык образы.

**Тема 31. Т.Миңнуллин тормыш һәм иҗат эшчәнлегенә гомуми күзәтү.**

реферат , примерные темы:

Т. МИҢНУЛЛИН (1935 -2012) Т.Миңнуллин - күренекле драматург, публицист, прозаик, әдәби хәрәкәтне әйдәп баручы.1960-1970 елларда язылган "Нигез ташлары"(1968), "Ир-егетләр"(1971), "Миләүшәнең туган көне"(1968), "Дуслар җыелган җирдә"(1978), "Хушыгыз"(1992) драмаларында вакыйгаларның тормышчанлыгы, заманның үзгәрешен сиземләү."Үзебез сайлаган язмыш" (1972). "Ай булмаса, йолдыз бар" (1977) "Монда тудык, монда үстек" (1982), драмаларында көчле рухлы шәхес концепциясе."Әлдермештән Әлмәндәр"(1976), "Әниләр һәм бәбиләр"(1984) пьесаларында кешенең дөньяда яшәвенең мәгънәсе, җәмгыять, якыннары, үз-үзе алдында җаваплылыгы, әхлакый сафлыгы, намуслылык мәсьәләләренең сәнгатьчә куелышы. Тарихи шәхесләргә багышлап язган "Канкай утлы Бәхтияр"(1974), "Моңлы бер җыр"(1981), "Без китәбез, сез каласыз"(1995) драмалары.Комедия жанрын үстерүдәге казанышлары. "Диләфрүзгә дүрт кияү"(1968), "Йөрәк маем"(1990), "Баҗа мал түгел, кәҗә туган түгел"(1994) "Гергөри кияүләре"(1995),.Соңгы елларда язылган "Илгизәр+Вера"(1992), "Шәҗәрә"(1998), "Саташу"(2001) һ.б. пьесаларында актуаль проблемаларның куелышы. Балалар өчен язылган пьесалар җыентыгы. Әдипнең проза һәм публицистика өлкәсендәге эшчәнлеге.

**Тема 32. Х.Туфан, С.Хәким иҗатларына гомуми күзәтү.**

устный опрос , примерные вопросы:

Хәсән Туфан. Иҗатына күзәтү. "Ә үткәнгә хатлар бармыйлар", "Кармәт истәлекләре". Әсәрләрнең төп проблематикасы һәм яңалыгы. Сибгат Хәким. Иҗатына күзәтү. "Гел кояшка карый тәрәзәләрем", "Башка берни дә кирәкми" шигырьләре. Әсәрләрдә туган якның бирелеше, аларда нечкә лиризм.С. Хәким - дистәләгән җырлар авторы. "Юксыну" (Ш. Мәҗитов музыкасы), "Фазыл чишмәсе", "Таң атканда" (халык көйләре), "Күңелем Ленин белән сөйләшә" (Х. Вәлиуллин музыкасы), "Башка берни дә кирәкми", "Кайда да йөрәктә" (М. Мозаффаров музыкасы), "Өзелгәнсең сиреньнән" (Н. Җиһанов музыкасы), "Бу кырлар, бу үзәннәрдә", "Кем уйлаган" (Җ. Фәйзи музыкасы), "Бер тауда ун чишмә" (Ә. Фәттах музыкасы) кебек җырлар халык арасында зур популярлык казандылар.

**Итоговая форма контроля**

экзамен (в 4 семестре)
**Итоговая форма контроля**
экзамен (в 8 семестре)
**Итоговая форма контроля**
экзамен (в 6 семестре)
**Итоговая форма контроля**
экзамен (в 3 семестре)
**Итоговая форма контроля**
экзамен (в 7 семестре)
**Итоговая форма контроля**
экзамен (в 2 семестре)
**Итоговая форма контроля**
экзамен (в 5 семестре)

Примерные вопросы к экзамену:
1.XX йөз башы әдәбиятының үзенчәлекләре
2.XX йөз башы әдәбиятының вакытлы матбугаты
3.XX йөз башында романтизм: аның үзенчәлекләре
4.Г.Исхакыйның башлангыч чор иҗаты
5.Г.Исхакыйның иҗатында миллилек
6.Әдип, публицист, журналист буларак Ф.Әмирхан
7.Ф.Әмирханның "Хәят"(1911) повестенда психологизм
8.Г.Ибраһимовның тормыш юлы: күпкырлы эшчәнлеге
9.Г.Ибраһимов иҗатында романтизм
10.Ш.Камал хикәяләрендә гади кешеләрнең тормышы
11.Ш.Камал иҗатында психологизм
12.Татар драматургиясенә нигез салучы буларак Г.Камал
13. XX йөз башы татар поэзиясенең характелы сыйфатлары
14.Г.Тукайның тормыш сукмаклары
15.Г.Тукай иҗатын чорларга бүлү
16.Г.Тукай иҗатының Казан чоры
17.М.Гафуриның башлангыч чор иҗаты
18.М.Гафури - мәсәлче
19.С.Рәмиев иҗатында экспрессионистик чаралар.
20.С.Рәмиев драматугиясе
21.Дәрдемәнд иҗатының фәлсәфилеге
22.Н.Думави иҗатында Көнбатыш һәм Көнчыгыш фәлсәфәсе
23.Ш.Бабич иҗаты (жанр төрлелеге, идея-тематик киңлек)
24.Г.Коләхмәтовның "Ике фикер"(1906) драмасында күтәрелгән мәсьәләләр.
25.М.Фәйзинең "Галиябану"(1916) музыкаль драмасында авыл яшьләренең бирелеше

### 7.1. Основная литература:

1. Яхин Ф.З. Әдәбият укыганда: фәнни тикшеренүләр [Электронный ресурс] / Ф.З. Яхин. -Казан: ?Сүз? нәшрияты, 2014. ? URL :https://dspace.kpfu.ru/xmlui/bitstream/handle/net/21807/978-5-98356-236 3.pdf?sequence=1&isAllowed=y

2. Яхин Ф.З. Гасырдан - гасырга: яңа заман әдәбиятына [Электронный ресурс] / Ф.З. Яхин. - Казан: ?Сүз? нәшрияты, 2014. - URL : https://dspace.kpfu.ru/xmlui/bitstream/handle/net/21806/978-5-98356-233-.pdf?sequence=1&isAllowed=y

3. Яхин Ф.З. Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбияты: югары уку йортлары һәм мәктәпләр өчендәреслек-кулланма. [Электронный ресурс] / Ф.З. Яхин. - Казан: Раннур, 2011. - 188 б. - URL : https://dspace.kpfu.ru/xmlui/bitstream/handle/net/22216/5-900049-74-4.pdf?sequence=1&isAllowed=y

## 7.2. Дополнительная литература:

1. Галимуллин Ф.Г. ГАЗИЗ ГУБАЙДУЛЛИН И ГАЛИМДЖАН ИБРАГИМОВ: ПОЛИТИЧЕСКИЕ И ЭСТЕТИЧЕСКИЕ ПРОТИВОРЕЧИЯ / Ф.Г. Галимуллин // ИСЛАМ И ТЮРКСКИЙ МИР: ПРОБЛЕМЫ ОБРАЗОВАНИЯ, ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ, ИСТОРИИ И РЕЛИГИИ. Материалы VIII Международной тюркологической конференции, 22.04.2016-22.04.2016. ? Казань, 2016. ? Режим доступа: https://dspace.kpfu.ru/xmlui/bitstream/handle/net/102981/ITWPELLHR_100_103.pdf?sequence=-1&isAllow

2. Галиуллин Т.Н. ?САЯХАТНАМЕ? - ЛИТЕРАТУРНОЕ ПУТЕШЕСТВИЕ В ИСТОРИЮ // Ученые записки КФУ. Гуманитарные науки. ? 2008. ? Т. 150. кн. 6. - С. 137-143. - URL: http://dspace.kpfu.ru/xmlui/bitstream/handle/net/25619/150_6_gum_15.pdf

3. Воронова Л.Я. Проблемы литературного образования молодежи в Казанском университете (кон. XIX - нач. XXв.) // Михаил Муравьев и его время: сборник статей и материалов Четвертой Всероссийской научно-практической конференции ?Михаил Муравьев и его время. Посвящение Союзу трех Поэтов: Гаврилы Державина, Николая Львова и Михаила Муравьева? / под ред. А.Н. Пашкурова, Л.Я. Вороновой, А.Ф. Галимуллиной. - Казань: РИЦ, 2013. - С. 123 ? 133. - URL:http://dspace.kpfu.ru/xmlui/bitstream/handle/net/34226/mnm13_123_133.pdf

## 7.3. Интернет-ресурсы:

Библиотека учебной и научной литературы - http://mon/tatarstan.ru/rus/info.php?d=20400

История литературы - http://www.world-shake.ru/ru/Encyclopaedia/3686.html

История родной литературы - http://www.tatknigafund.ru

История родной литературы - http://pandia.ru/text/79/235/57857.php

Китапханә - http://miras.belem.ru/

## 8. Материально-техническое обеспечение дисциплины(модуля)

Освоение дисциплины "История родной литературы" предполагает использование следующего материально-технического обеспечения:

Мультимедийная аудитория, вместимостью более 60 человек. Мультимедийная аудитория состоит из интегрированных инженерных систем с единой системой управления, оснащенная современными средствами воспроизведения и визуализации любой видео и аудио информации, получения и передачи электронных документов. Типовая комплектация мультимедийной аудитории состоит из: мультимедийного проектора, автоматизированного проекционного экрана, акустической системы, а также интерактивной трибуны преподавателя, включающей тач-скрин монитор с диагональю не менее 22 дюймов, персональный компьютер (с техническими характеристиками не ниже Intel Core i3-2100, DDR3 4096Mb, 500Gb), конференц-микрофон, беспроводной микрофон, блок управления оборудованием, интерфейсы подключения: USB,audio, HDMI. Интерактивная трибуна преподавателя является ключевым элементом управления, объединяющим все устройства в единую систему, и служит полноценным рабочим местом преподавателя. Преподаватель имеет возможность легко управлять всей системой, не отходя от трибуны, что позволяет проводить лекции, практические занятия, презентации, вебинары, конференции и другие виды аудиторной нагрузки обучающихся в удобной и доступной для них форме с применением современных интерактивных средств обучения, в том числе с использованием в процессе обучения всех корпоративных ресурсов. Мультимедийная аудитория также оснащена широкополосным доступом в сеть интернет. Компьютерное оборудованием имеет соответствующее лицензионное программное обеспечение.

электронная библиотечная система "БиблиоРоссика"

электронная библиотечная система "ZNANIUM.COM"

Программа составлена в соответствии с требованиями ФГОС ВПО и учебным планом по направлению 44.03.01 "Педагогическое образование" и профилю подготовки Родной язык и литература .


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Автор(ы):
Габидуллина Ф.И. ____________________
Мухаметзянова А.Х. ____________________
Даутов Г.Ф. ____________________
"__" _________ 201 __ г.

Рецензент(ы):
Галиуллина Радик Рамилевич ____________________
"__" _________ 201 __ г.